**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

__________ 19.06.2024 № ПР-111 № ___

**«Мәктәп автобус маршрутларын тикшерү турында»**

Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөрткәндә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында, юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары (юл билгеләре, ясалма тигезсезлекләр һәм юнәлеш бирүче җайланмаларның) булуын, дөреслеген, урнаштырылуын тикшерү максатыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемнәрен автобуслар белән оешкан рәвештә йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 сентябрендәге 1527 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Тәкъдимнәр җибәрү турында» 2020 елның 19 мартындагы 3432/20 номерлы хаты нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Мәктәп автобусларының хәрәкәт итү маршрутларында юл шартларын, юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын белем бирү учреждениеләренә турыдан-туры якын җирдә урнаштыру һәм аларның төзеклеген тикшерү буенча 1 нче кушымта нигезендә ведомствоара комиссия төзергә.

2. Ведомствоара комиссия турында нигезләмәне әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Муниципаль берәмлек территориясендә мәктәп автобусларының маршрутларын расларга (3 нче кушымта).

4. 2024 елның 25 июненнән 2024 елның 27 июненә кадәр мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутларында, юл шартларын тикшерү буенча комиссиясенә мәктәп маршрутларында юл шартларын тикшерүне үткәрергә.

5. «Мәктәп автобус маршрутларын тикшерү турында» 2023 елның 20 июлендәге ПР-110 номерлы карарны үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.М.Анваровага йөкләргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җитәкче Р.А.Ильясов

ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе карарына
______________ 2024 ел N____
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2024 елның 25 июненнән 27 июненә кадәр мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутларында юл шартларын тикшерү буенча ведомствоара комиссиясе**

Ильясов Рөстәм Алмаз улы - Актаныш районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

Шәмсиев Ренат Радик улы - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча ЮХИДИ бүлекчәсе башлыгы, полиция капитаны (килешү буенча);

Идрисов Ришат Илшат улы - «Татавтодор» АҖ Минзәлә филиалының Актаныш юл төзекләндерү-төзелеш участогы башлыгы (килешү буенча);

Заһретдинов Алмаз Илфак улы - «Актаныш АТХ» муниципаль унитар предприятиесенең транспорт чарасын эксплуатацияләү инженеры;

Гайсина Гүзәл Зиннур кызы - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең баш белгече;

Билгеләнгән махсус мәктәп автобуслары хезмәтләреннән файдаланучы укучы балалары булган - мәктәп директорлары.

ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе карарына
____________ 2024 ел №____
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә мәктәп автобусларының хәрәкәт маршрутларында юл шартларын тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутларында юл шартларын тикшерү буенча Комиссия (алга таба – Комиссия) автомобиль юлларының, ясалма юл корылмаларының техник торышын һәм тоту дәрәҗәсен мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутларында йөргәндә юл хәрәкәте куркынычсызлыгы таләпләренә туры килүен бәяләү максатыннан оештырылды.

2. Комиссия үз эшчәнлеген «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 03 августындагы 400 номерлы карары һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә гамәлдә булган башка норматив актлар нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Комиссиянең төп бурычы - мәктәп автобуслары маршрутларында (алга таба - маршрут) аларны ачу алдыннан һәм эксплуатацияләү процессында гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә юл шартларын тикшерү.

4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

4.1. Маршрутларның юл хәрәкәте куркынычсызлыгы таләпләренә туры килүен түбәндәгеләр нигезендә билгели:

тикшерү маршрутында йөртүне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары тәкъдим иткән маршрут турында мәгълүмат;

юл оешмалары тарафыннан тапшырылган, алар карамагында юллар, ясалма корылмалар булган юл оешмалары тарафыннан тапшырылган маршрутта (юл йөрү өлешенең параметрлары һәм торышы, юл кырыйлары, план элементлары һәм юл профильләре, интенсивлык һәм хәрәкәт составы, ясалма юл корылмаларының торышы һ.б.лар) юл шартлары турында мәгълүматлар;

маршрут буенча контроль йөреп чыгу процессында визуаль тикшерү һәм инструменталь үлчәүләр аша турыдан-туры тикшерү.

4.2. Юл шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча маршрутларда түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

тикшерелгән маршрутның юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү таләпләренә туры килүе турында;

яңа маршрут ачу мөмкинлеге турында (яңа маршрутлар ачу мәсьәләләрен караганда).

4.3. Маршрутларның юл хәрәкәте куркынычсызлыгы таләпләренә туры килмәве ачыкланган очракта, юл хәрәкәте шартларын яхшыртуга һәм маршрутта юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтүгә юнәлдерелгән кичектергесез һәм перспектив чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр эшли.

5. Маршрутларда юл шартларын тикшерү елга кимендә ике тапкыр (көзге-кышкы һәм язгы-җәйге чорга) гамәлгә ашырыла.

6. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

6.1. Дәүләт юл хәрәкәте иминлеге инспекциясе органнарыннан, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалардан Комиссиягә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне соратып алырга;

6.2. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм Комиссия эшендә катнашу мәсьәләләрен өйрәнү өчен белгечләр җәлеп итәргә;

6.3. Комиссия эшенә юл-эксплуатация хезмәтләре вәкилләрен җәлеп итәргә;

6.4. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән тиешле органнарга юл хәрәкәте иминлеге мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертергә.

Комиссияне комиссия эше белән җитәкчелек итүче рәис җитәкли.

8. Комиссия карары аның маршрутны тикшерүдә катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана торган тикшерү актына кертелә.

9. Тикшерү актларын рәсмиләштерү маршрутны тикшерү тәмамланганнан соң биш көнгә кадәр гамәлгә ашырыла.

10. Тикшерү актларының күчермәләре, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча кичектергесез чаралар үткәрү өчен юллар, урамнар, ясалма юл корылмалары булган юл,

коммуналь оешмаларга һәм авыл җирлекләре башлыкларына җибәрелә. Шулай ук хәрәкәт итүче составның юл шартларына туры килүен тәэмин итү, йөртүчеләргә инструктажлар үткәрү, куркыныч участокларның схемаларын төгәлләү, хәрәкәт тизлеген нормалаштыру (коррекцияләү) өчен тикшерелә торган маршрутларда ташуны гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешмаларга.

11. Комиссия эшен оештыруны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тәэмин итә.

ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
__________2024 ел №_____
3 нче кушымта

**ТР Актаныш муниципаль районы территориясендә махсус мәктәп автобуслары маршрутлары исемлеге**

1. «Татар-Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе»1 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
2. «Актаныш 1 санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе»2 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
3. «2 санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» 2 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
4. «2 санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе»2 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
5. «2 санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» 2 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
6. «Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» 3 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
7. «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» 4 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
8. «1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» 5 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты; (2 нче автобус)
9. «Югары Яхшый төп гомуми белем бирү мәктәбе» 6 нчы эчке муниципаль махсус мәктәп мәктәп маршруты;
10. «Киров урта гомуми белем бирү мәктәбе» 7 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
11. «Әтәс төп гомуми белем бирү мәктәбе» 8 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты
12. «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» 9 нчы эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
13. «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» 9 нчы эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
14. «Богады төп гомуми белем бирү мәктәбе» 10 нчы эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
15. «Сәфәр урта гомуми белем бирү мәктәбе» 11 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
16. «Теләкәй төп гомуми белем бирү мәктәбе» 12 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
17. «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» 13 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
18. «Аккүз төп гомуми белем бирү мәктәбе» - «Меңнәр төп гомуми белем бирү мәктәбе» 14 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
19. «Яңа Әлем төп гомуми белем бирү мәктәбе» 15 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;